**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**
**Татарстан Республикасы**
**Баулы муниципаль районы**
**Яңа Зареченск авыл җирлегенең**
**Дмитриевка авылы торак пунктында**

2023 нче елның 22нчы ноябрь № 6

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Яңа Зареченск авыл җирлегенең Дмитриевка авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Яңа Зареченск авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән, көндезге формада белем алучы студентлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, 1нче төркем инвалидлардан, 75тән өлкәнрәк яшьтәге ялгыз яшәүче гражданнардан тыш, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылганнар яки контракт буенча хәрби хезмәткә кергәннәр яки Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә (свода катнашучылар), 2024 елда 500 сум күләмендә үзсалым кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Кышкы чорда Дмитриевка авылында юлларны карап тоту (кардан чистарту);
- Дмитриевка авылындагы урамнарны яктырту хезмәте күрсәтү (терәкләр урнаштыру, ремонт, урам утларын алыштыру).

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яна Зареченск авыл җирлеге башлыгы А.Р. Зәбирова